| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**<br>**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«12» гыйнвар 2018 ел № 26

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар планын ("Юл картасын") раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 5 сентябрендәге 1738-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Россия Федерациясе субъектларында көндәшлекне үстерү стандарты таләпләрен үтәү йөзеннән, көндәшлекне үстерүгә һәм Нурлат муниципаль районында көндәшлекнең торышы турында системалы аналитик мәгълүмат белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән актуаль дәүләт сәясәтен формалаштыру зарурилыгы максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында көндәшлекне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар планын ("Юл картасын") раслау турында.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К.ГАБДУЛЛИН

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 12 гыйнварындагы 26 номерлы карарына 1 нче кушымта

# 2018-2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА КӨНДӘШЛЕКНЕ ҮСТЕРҮГӘ ЯРДӘМ ИТҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ПЛАНЫ ("ЮЛ КАРТАСЫ")

| N т/с | Бурычларны үтәү өчен чараның исеме | Җаваплы башкаручылар һәм төп катнашучылар | Чараны тормышка ашыру вакыты | Максатчан индикаторлар |
|---|---|---|---|---|
| Социаль әһәмиятле базарларда көндәшлекне үстерү | | | | |
| Балаларга мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләре базары | | | | |
| Нурлат муниципаль районында 29 балалар бакчасы һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә 13 мәктәпкәчә төркем эшли. 2017 елның 1 июленә мәктәпкәчә белем бирү 68,5% тәшкил итә | | | | |
| | Проблема: авыл балалар бакчаларының кечкенә контингенты | Бурыч: авыл балалар бакчалары контингентын арттыру, мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләренең сыйфатын арттыру.<br><br>Максат: мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын күтәрү, авыл җирлегендә 3-7 яшьлек балаларга мәктәпкәчә белем бирүнең 100%ын колачлау | | |
| 1 | методик эшне оештыру өчен мәктәпкәчә төп учреждениеләрдә аз комплектлы балалар бакчаларын беркетү | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге | 2018 - 2020 еллар | Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләреннән халыкның канәгатьлеген күтәрү, авыл балалар бакчалары контингентын арттыру |
| Балалар ялы һәм сәламәтләндерү хезмәтләре базары | | | | |
| Нурлат муниципаль районында 31 лагерь эшли: 3 лагерь - "Чияле Алан", "Заречный", "Лучезарный", 2 палаткалы лагерь: "Ратный сбор", "Патриот", 23 көндезге лагерь, 3 хезмәт һәм ял лагере. | | | | |
| | Проблема: район халкының балалар һәм яшьләрнең ялы өлкәсендә сыйфатлы хезмәт күрсәтүләре белән канәгатьлеген күтәрү | Бурыч: төрле ял итү, сәламәтләндерү һәм мәшгульлек төрләрендә булган балалар санын арттыру.<br><br>Максат: ял итү һәм сәламәтләндерү системасын үстерү, ял һәм сәламәтләндерүне гамәлгә ашыручы оешмаларның матди-техник базасын ныгыту | | |
| 1 | Ата-аналарның матди хәленә һәм социаль статусына карамастан, балаларның ял итәргә һәм сәламәтләндерүгә | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма | 2018 - 2020 еллар | Нурлат районы территориясендә яшәүче, балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү хокукыннан |

<table>
<tr><td></td><td>хокукларын тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү буенча ТР ХМР башкарма комитеты белән хезмәттәшлек итү. Балаларның ялын оештыруга районның җирле бюджетыннан акчалар бүлү</td><td>комитеты,<br><br>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр бүлеге, балалар һәм яшьләр ялы учреждениеләре балансында булган предприятиеләр һәм оешмалар</td><td></td><td>файдаланучы 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балалар саны:<br><br>2017 елда - 2210;<br><br>2018 елда - 2060;<br><br>2019 елда - 2070;<br><br>2020 елда - 2080</td></tr>
<tr><td colspan="5" align="center">Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре базары</td></tr>
<tr><td colspan="5">Нурлат муниципаль районында төрле милек рәвешләрендәге 11 коммуналь оешма эшчәнлек алып бара</td></tr>
<tr><td></td><td>Проблема: коммуналь инфраструктураның техник яктан тузу дәрәҗәсе югары, куәтләрнең файдалы эш коэффициенты түбән һәм энергия чыганакларының зур чыгымнары</td><td colspan="3">Бурыч: торак-коммуналь хуҗалык базарында конкуренцияне үстерү өчен шартлар тудыру, икътисадның күрсәтелгән секторларында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итүче факторлар буларак энергетика нәтиҗәлелеген модернизацияләү һәм стимуллаштыру.<br><br>Максат: торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Торак-коммуналь хуҗалык объектларының нәтиҗәле булмаган идарәне гамәлгә ашыручы барлык дәүләт һәм муниципаль предприятиеләрнең концессион килешүләре нигезендә хосусый операторлар идарәсенә тапшыру</td><td>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлеге</td><td>2018 - 2020 еллар</td><td>Концессия килешүләре, берәмлекләр нигезендә торак-коммуналь хуҗалык объектларын тапшыру:<br><br>2018 елда - 1;<br><br>2019 елда - 1;<br><br>2020 елда - 1</td></tr>
<tr><td colspan="5" align="center">Җир өсте транспортында пассажирлар йөртү хезмәтләре базары</td></tr>
<tr><td colspan="5">Нурлат муниципаль районында автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне 1 оешма башкара</td></tr>
<tr><td></td><td>Проблема: транспорт предприятиеләре чыгымнарын бәяләүнең нәтиҗәле системасы булмау, район территориясендә гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның зыянлыгы</td><td colspan="3">Бурыч: даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда конкурентлык мохитен үстерү.<br><br>Максат: даими рәвештә транспорт йөртүләрдә халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерү</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Муниципаль һәм муниципаль дәрәҗәдә</td><td>Татарстан Республикасы</td><td>2018 - 2020 еллар</td><td>Яңа муниципаль һәм муниципальара</td></tr>
</table>

<table>
<tr><td></td><td>пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда конкурентлык мохитен үстерү</td><td>Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты,<br><br>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлеге</td><td></td><td>маршрутлар ачу:<br><br>2017 елда - 1;<br><br>2018 елда - 1;<br><br>2019 елда - 1;<br><br>2020 елда - 1</td></tr>
<tr><td colspan="5" align="center">Ваклап сату базары</td></tr>
<tr><td colspan="5">Сәүдә секторы районда иң динамикалы үсүче предприятиеләрнең берсе булып тора һәм 600 дән артык юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны берләштерә. Сәүдә тармагын эре сәүдә челтәрләре дә, вак җир предприятиеләре дә тәкъдим итә.<br><br>Районның кече һәм урта бизнес вәкилләренең 50%ка якыны сәүдә өлкәсендә эшли.<br><br>2017 елның 9 аенда ваклап сату әйләнеше 7,4 млрд. сум тәшкил итте.<br><br>Ел саен Нурлат муниципаль районында авыл хуҗалыгы ярминкәләре уздырыла, аларда авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре үзләре җитештергән товарларны сата. 2017 ел башыннан 15 авыл хуҗалыгы ярминкәсе үткәрелде, сатылган продукция күләме 12,5 млн сум тәшкил итте.</td></tr>
<tr><td></td><td>Проблема: кулланучылар активлыгын кимету, халыкның керемнәре киму, халыкның кредитлануы; бәяләр арту</td><td colspan="3">Бурыч: ваклап сату өлкәсендә намуслы конкуренцияне үстерү; авыл хуҗалыгы продукциясенә (чималга) һәм эшкәртү продуктларына бәяләрне мониторинглау; җирле авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре продукциясен сату өчен агросәнәгать базарларын ачу.<br><br>Максат: продукциянең конкурентлыкка сәләтлелеген арттыруда һәм реализацияләүдә КУЭ ярдәм итүнең мәгълүмати һәм оештыру системасын формалаштыру</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан яңа сәүдә объектларын ачу</td><td>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты,<br><br>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге</td><td>2018 - 2020 еллар</td><td>Сәүдәнең яңа объектлары саны, берәмлекләр:<br><br>2017 елда - 6;<br><br>2018 елда - 2;<br><br>2019 елда - 2;<br><br>2020 елда - 2</td></tr>
<tr><td>2</td><td>Ярминкәләр үткәрү һәм ваклап сату базарларында һәм ярминкәләрдә ваклап сату сәүдәсен гамәлгә</td><td>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма</td><td>2018 - 2020 еллар</td><td>Үткәрелгән ярминкәләр саны, берәмлек:</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ашыру мөмкинлеген тәэмин итү | комитеты,<br><br>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | | 2017 елда - 6;<br><br>2018 елда - 7;<br><br>2019 елда - 9;<br><br>2020 елда - 11 |
| 3 | Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең ярминкәләрдә үз продукциясен сатуларын арттыру, шулай ук сатыла торган продукциягә бәяләр билгеләү буенча гражданнарның ирекле ихтыяр белдерүләрен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты,<br><br>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | 2018 – 2020еллар | Ярминкәләрдә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең үз продукциясен сату күләменең алдагы ел белән чагыштырганда , артуы,%:<br><br>2017 елда - 101,0;<br><br>2018 елда - 103,0;<br><br>2019 елда - 105,0;<br><br>2020 елда - 106,0 |
| 4 | Районның челтәр кибетләрендә җирле җитештерүчеләрнең товарларын сатуны арттыру чараларын гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты,<br><br>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге | 2018 - 2020 еллар | Районның челтәр кибетләрендә җирле җитештерүчеләрнең товар әйләнеше күләме арту:<br><br>2018 ел - 102%;<br><br>2019 ел - 103%;<br><br>2020 ел - 104% |
| Ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгы кошлары җитештерү базары | | | | |
| Нурлат муниципаль районы территориясендә ит һәм ит продуктлары җитештерү белән 50дән артык авыл хуҗалыгы җитештерүчесе шөгыльләнә | | | | |
| | Проблема: ит, ит продуктларын һәм авыл | Бурыч: терлекчелек һәм кошчылык өлкәсендә кече хуҗалыкларны (крестьян (фермер) хуҗалыкларын, шәхси | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хуҗалыгы кошларын җитештерү базары конкуренциягә сәләтлелек дәрәҗәсен үстерү күзлегеннән чыгып, зәгыйфьлекнең югары дәрәҗәсе белән характерлана | ярдәмче хуҗалыкларны, гаилә фермаларын) үстерү.<br><br>Максат: җирле производство продукциясе өлешен арттыру | | |
| 1 | Ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгы кошлары җитештерүне оештыру өлкәсендә эшкуарлыкның кече формаларын үстерү | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты,<br><br>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | 2018 - 2020 еллар | Узган елга кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгы кошлары җитештерүнең артуы, %:<br><br>2017 елда - 4;<br><br>2018 елда - 5;<br><br>2019 елда - 5,5;<br><br>2020 елда - 6 |
| 2 | Ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгы кошлары җитештерү буенча районның гамәлдәге комплексларын яңаларын булдыру һәм модернизацияләү | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты,<br><br>Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | 2018 - 2020 еллар | Ит, ит продуктлары һәм авыл хуҗалыгы кошлары, берәмлекләр җитештерү буенча районның гамәлдәге комплексларын төзү һәм модернизацияләү:<br><br>2018 елда - 1;<br><br>2019 елда - 1;<br><br>2020 елда - 2 |
| Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр базары | | | | |
| Нурлат муниципаль районында 100 структур бүлекчәдән торган 3 (өч) муниципаль мәдәният учреждениеләре челтәре эшли | | | | |
| | Проблема: мәдәни проектларны гамәлгә ашыру эшчәнлеген активлаштыруга карамастан, әлеге өлкәдә конкуренция дәрәҗәсе шактый түбән булуы билгеләнә. | Бурыч: театр-тамаша учреждениеләре уздырган чараларның гомуми санында коммерция оешмалары уздыра торган чаралар өлешен арттыру.<br><br>Максат: мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә конкуренцияне үстерү өчен шартлар тудыру, сәнгатьнең төрле юнәлешләре буенча мәдәни продуктның күптөрлелеген арттыру (мәгариф, музыка, театр, хореография сәнгате, кино һ.б.) | | |
| 1 | Мәдәният өлкәсендә конкуренцияне үстерү өчен шартлар тудыру | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль | 2018 - 2020 еллар | Нурлат муниципаль районында театр-тамаша учреждениеләре үткәрә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | районы башкарма комитеты,<br><br>"Мәдәният үсеше үзәге" МБУ;<br><br>"Нурлат балалар сәнгать мәктәбе" өстәмә белем бирү МБУ;<br><br>"Шәһәрара үзәк китапханә" МБУ | | торган чараларның гомуми күләмендә коммерция оешмалары уздыра торган чаралар өлеше, %:<br><br>2018 елда - 1,2;<br><br>2019 елда - 1,24;<br><br>2020 елда - 1,33 |
| Туризм өлкәсендә хезмәтләр базары | | | | |
| Нурлат муниципаль районы территориясендә Республика буйсынуындагы объектлар - 7 объект мәдәни мирас ядкәрләре, шулай ук археология, табигать, архитектура, тарих һәм мәдәният һәйкәлләре бар. | | | | |
| | Проблема: туризм өлкәсе җитәрлек үсеш алмаган | Задача: продвижение рынка услуг в сфере туризма. Цель: увеличение туристического потока | | |
| 1 | Туризм үсеше, туристик маршрутлар эшләү | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты, Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы төбәк музее;<br><br>Г. Кариев исемендәге Колбай-Мораса тарих музее | 2018 - 2020 еллар | Узган елга туристлар агымы үсеше, %:<br><br>2018 елда-7;<br><br>2019 елда-12;<br><br>2020 елда-15 |